**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«10» 03 2022 ел № 694

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегенең генераль планы проектына үзгәрешләр кертү буенча документларны эшли башлау турында

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлеге территориясен тотрыклы үстерү мәсьәләләрен җайга салу максатында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 25 декабрендәге 38/6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Троицкий авыл җирлегенең генераль планы проектына үзгәрешләр кертү буенча документларны эшли башларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин